СОВЕТ УРМАНЧЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 3-15 22 июнь, 2022 ел

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 05.06.2018 №6-35, от 29.04.2019 №3-44, от 19.02.2020 № 5-53 номерлы карарларын гамәлдән чыгару турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Мамадыш районы прокуратурасының Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 5 нче июнендә кабул ителгән 6-35 номерлы карарына карта 2022 елның 25 маендагы № 02-08-02-2022 протесты, Урманчы авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 апрелендәге №3-44 номерлы карарына карата 2022 елның 25 маендагы № 02-08-02-2022 протесты, Урманчы авыл җирлеге Советының 2020 елның 19 февралендәге № 5-53 номерлы карарына карата 2022 елның 26 маендагы № 02-08-02-2022 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

- 2018 елның 5 июнендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 декабрендәге 3-45 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 6-35 номерлы карарын;
- 2019 елның 29 апрелендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану

һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 3-44 номерлы карарын;

- 2020 елның 19 февралендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 декабрендә кабул ителгән 3-45 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турындагы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» № 5-53 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, "Интернет" мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштырырга.

3.. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе ______________/ А.Я.Ильин